Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ НОЯБРЬ * 2023 * КАЗАН

11



Александр ШУЛЬПИНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

НОЯБРЬ ҮЗГӘЛЕГЕ...

Ноябрь аеның кирәген
Йә, кем белә тасвирлый?
Ул бит табигатьтән гайре
Яшәештә роль уйный.

Инде күпме еллар буе
Көрсендереп җил өрә,
Яңгыр катыш карлар ява –
Шулмы безгә ямь бирә?

Гел алай да булалмый,
Яз да елга бер килә.
Җәй дә үз чираты белән
Күзгә күчәсен белә.

Шулай алмашынып тору,
Ял иттерү бер-берсен,
Ихтирам диеп беләбез –
Барсы да безнең өчен.

Хәтта Октябрь бәйрәмен дә
Үткәрәбез шул айда.
Ноябрьгә кергәч була бит
Ил тетрәткеч вакыйга!..

Бар эксплуататорларны
Хакимлектән куганнар.
Яңа тормыш нигезләүче
Социализм корганнар.


Илдә гаделлек тантана
Иткән чак бу, ниһаять.
Хезмәт кешесен данлауга
Бирелгән әһәмият!

Индустрияләштерүнең
Башы шуннан башланган.
Һәркем укып белем алган,
Илдә надан калмаган.

Явыз дошман бәреп кергәч,
Белемле, аңлы халык,
Чәчәк аткан үз Ватанын
Саклаган җанын кылып.

Без хәзер дә әзер шулай
Илебезне якларга.
Бабабызның, әтиләрнең
Яулаганын югалтмыйча,
Васыятьләрен акларга!

Александр АЛЁШИН



ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел Россия Федерациясенең Җинаять кодексында яңа маддә барлыкка килде. Аның буенча «Кызыл китап»ка кергән гөмбәләрне җыйган, сатып алган һәм саткан өчен тугыз елга кадәр срок алырга йә өч миллион штрафка тартылырга була. Дөрес, бу «оешкан шәхесләр төркеме» өчен генә. Ә гади гөмбә сөючеләр өчен йомшаграк административ җаваплылык каралган...

Л. СӘЛИМОВ

ТҮБӘН КАМА

– Хәзер кызыл китаптагы гөмбәләрне саклап калу кызыл китаптагы олигархларны саклауга караганда җиңелрәк булачак, – диде Шомбай ага, укучыбызның хаты белән танышкач.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Эшегезне никадәр яхшы башкарсагыз да, җитәкчегез аның нәтиҗәләрен төзәтергә тырышачак.

Бюрократия белән бюрократия гына чынлап көрәшә ала.

Утырышта тәнәфес ясау тәкъдиме һәрвакыт уңай кабул ителә.

Тәҗрибә кирәк булганда, аны тупларга инде соң була.

Прогресс ул – бер уңайсызлыкны икенчесенә алыштыру.


Гомерне алга карап үтәргә кирәк. Ләкин аны аңлар өчен, артка борылып карау кирәк.

Акыллылар – хаклык тапкач, ә ахмаклар ялган тапкач шатлана.

Әгәр барган юлыгыз тигез икән, димәк, сез дөрес юлдан бармыйсыз.

(Тәҗрибәлеләр мәҗлесендә язып алынды.)

Илдар НӘФИЕВ



Ринат АБЗАЛОВ



Кагыйдәсез сугыш

Гасырлардан килгән гадәт буенча, һәр җыелышып "тамак чылату" егетләрчә йодрык уйнату һәм ахырда татулашу белән тәмамланырга тиеш. Бу гадәт урта гасырларда тамыр җибәргән, ә кайнар канлы ирләрнең бәрелешләре хикәятләрдә, әкиятләрдә һәм кыйссаларда искә алынган. Әмма ул чакларда сугышулар язылмаган кагыйдәләр кысасында барган, ә ул кагыйдәләрне бозу җәмгыять тарафыннан кабул ителмәгән. Ә бүгенге барча тыюларны юкка чыгарган рәхимсез гасырда көндәшләр, башка сыймый торган кешелексезлек белән ахыргача бәрешә…

Азнакай районында чибәр ханымны бүлешә алмаган ике кыдрач ирнең бәрелеше бик күңелсез тәмамланган. Хәмер белән көчәйтелгән сүз бәхәсе чигеннән чыккач, эшкә йодрыклар җигелгән. Нәтиҗәдә, яшьлек тәҗрибәдән көчлерәк булып чыккан: 32 яшьлек егет 59 яшьлек фатир хуҗасына шулай итеп тондырган ки, тегесе шунда ук җан биргән. Шулай итеп, гүзәл ханым беркемгә дә эләкми калган.

Әйтергә кирәк, романтика белән сугарылган җан халәте еш кына исерек сугышуларга китерә. Ике Казан хатыны белән нәкъ шулай килеп чыккан да. Алар кафеда күңел ачып утырганнар. Ә күрше өстәл янында әдип һәм музыкант әңгәмә корган. Каннары кызган ханымнар аларга кичне бергә уздырырга тәкъдим иткәннәр. Ләкин, сәнгать турында сөйләшүне артык күреп, ирләр тәкъдимне кире какканнар. Нәтиҗәдә хәтерләре калган гүзәлләр аларның берсенең башына, икенчесенең кулына шешә белән биргәннәр. Мәҗлесне дәвам итәсе урынга һәркем үз юлы белән – сәнгать әһелләре хастаханәгә, ә җан җәрәхәте алган ханымнар полициягә киткән.

Иҗади шәхесләр белән ниләр генә булмый! Казанда кызып киткән бер тамада, шәһәр рестораннарының берсендә мәҗлесне җанландырып җибәрергә булган. Моның өчен ул, озак уйлап тормыйча, кунакларның берсенә урындык томырган. Ул максатына ирешкән – тамаданың үзенә савыт-саба һәм кашыкчәнечкеләр оча башлаган. Дусларча бәрелеш өчен сәбәп табылган.

Адоратский урамындагы шаурма кафесында өч "салмыш" бәндә тәннәрен язылдыру өчен бик үзенчәлекле сәбәп тапканнар. Хезмәт күрсәтүченең үз телендә сөйләшүендә алар… татарча сүгенү сүзләре ишеткәннәр. Нәтиҗәдә, зыян күргән сатучы хастаханәгә мөрәҗәгать иткән, ә бераз соңрак тегеләре дә шунда ук килеп җиткән – сугышкан чакта аларның берсе кулын сындырган булып чыккан.


Шундый күңелсез шаукымнарга карамастан, өстәл янында шешә белән утыру ватандашларыбызның иң яраткан шөгыле булып кала. Театрга барып булмый бит инде! Өстәвенә, эчәргә сәбәп табылып кына тора. Һәр көн диярлек – бәйрәм! Йә стакан уйлап чыгарылган көн, йә Менделеевның туган көне. Телисең икән – эч, теләмисең икән – барыбер эч! Ә мондый мәҗлесләрдән соң кагыйдәсез сугышларга ярты гына адым…

Людмила САФИУЛЛИНА



Игорь КИЙКО

Михаил ЛАРИЧЕВ



Николай ВОРОНЦОВ





● ● ●

Проект өчен никадәр күбрәк миллиардлар кертсәләр, шулкадәр күбрәк җитмәүчелек арта.

● ● ●

Хәзер юлларда шундый тәртипсезлек – хәтта права сатып алырга да куркыныч!

● ● ●

– Юләр инде мин, ни өчен сиңа кияүгә чыктым!

– Ә мин сиңа өйләнгәнемә үкенеп бетә алмыйм...

Уллары:

– Икегез дә юләр, ә үзегез минем яхшы укуымны телисез.

● ● ●

Бабай табибка күренергә килгән:

– Нәрсәгә зарланасыз? – дип сорый табиб.

– Йөрәккә. Берсенә менәм – ярыйсы. Икенчесенә – сулыш каба башлый. Өченчесенә – инде булдыра алмыйм...

– Ну, сез, әти кеше, герой! Мин сездән 30 яшькә кечерәк, минем көчкә берсенә хәл җитә.

– Сез нәрсә турында, доктор?

– Хатын-кызлар, инде...

– Мин бит баскыч буйлап менү авырлыгын сөйлим...

● ● ●

– Хәзер ни өчен гел салкын тидерүемне аңладым.

– Ну?

– Минем бит күңелем ачык яка шикелле.

● ● ●

Укытучы – дәрестә:

– Ә монысын үзегезнең репетиторларыгыз белән ачыклап чишәрсез.

● ● ●

– Өй эше итеп бирелгән иншаны улыгыз чынлап үзе яздымы?

– Ә сез бездән җыйган акчаны чынлап тәрәзә пәрдәләре өчен тоттыгызмы?

● ● ●

– Нишләп үз артыңнан карамыйсың?

– Ә мин бернәрсәдән дә шикләнмим.

● ● ●

– Әй каһәр, бөтен нәрсә кыйбатлана! Бәрәңге дә, крахмал да, он да һәм арпа да... Бу хәлдән ничек котылырга да белмим...

Александр БРЮХАНОВ

РОМАН ЯЗУНЫҢ БӘХЕТЕ...

Кайвакыт кыска гына кызык язсаң да, эч катып көләргә була. Ә инде шуңа искитәрлек персонажлар өстәсәң, мәзәкле вакыйга килеп чыга. Әгәр дә шул очракка каяндыр кереш сүзләр өстәсәң – ягъни мәсәлән, ул персонажларның ничек пәйда булуларын тасвирласаң, моны инде тулы бер хикәя дип исәпләргә мөмкин.

Әле табигатьнең гүзәллеген дә гаҗәеп оста сурәтләп күрсәтә белсәң, бу хәлләрнең кайда баруын чагылдырасың һәм дә кемнәр белән икәнен дә кушып җибәрсәң, мөгаен, бер яхшы гына бәян туарга да күп калмас...


Шуннан соң әлеге бәянга авторның төрле уйлануларын да бәйнә-бәйнә язсаң, ни өчен шундый кискен моментлар килеп туган, моңа кем гаепле һәм башка чатаклыклар кертсәң... Геройларның кайберләре трактор астына эләгеп үлеп тә китсә, бу чакта инде әсәрең романга әверелә һәм син аны, акчаң күп булган очракта, нәшер итәргә мөмкинсең, әлбәттә инде, югары даирәләрдә, танышларың ярдәмендә.

Ләкин мондый мөмкинлектән соң да китабыңны сата алмасаң, барлык тиражын макулатурага тапшыра аласың. Иманым камил, кабул итеп алучының шатлыклы йөзен күрү бәхетенә ирешә алачаксыз, һичшиксез!..

Вячеслав ШИЛОВ



Виктор БОГОРАД



Рөстәм ЗАРИПОВ

• • •


Бездә әле бәяләргә
Үсәсе дә үсәсе,
Шуны тели капиотларның
Бүксәсе һәм кесәсе...

"Кызыл билет"лылар басты
Форбс журналы түрен,
Әтрәгәләм ансат кичә
Оятсызлыкның үрен...

Нәфесе зур агайларның
Вөжданнары кечтеки, –
Авыл халкы саткан сөткә
Бәя шуңа – печтеки...

Коммунистик рух, асылда –
Җилгә каршы иткән пес,
Материя – беренчел шул,
Бик дөрес әйткән Маркс...

Максим СМАГИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО





ПЫЧРАТУ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ

Быел әйләнә-тирә мохитне пычраткан өчен республикадагы предприятие һәм оешмаларга 121 миллион сум штраф салынган. Шул ук вакытта табигатькә китерелгән зыян миллиардтан артык дип исәпләнә. Төп пычратучылар исемлегендә 960 миллионы белән "Звениговский" авыл хуҗалыгы кооперативы беренчелекне тота. Аннан соң "ПЖКХ" чүп кооперативы һәм "Татнефть" акционерлык җәмгыяте бара – аларның гомуми штрафтагы өлеше 28 һәм 24 миллион сум.

АКЧА БАШ БУЛГАНДА

Медикларга да кешелек сыйфатлары ят түгел. Татарстанда коррупциягә каршы көрәш әһелләре дәвалау өлкәсендә кыек эшләр таканнар. Мәсәлән, мәҗбүри иминиятләштерү фондына кыйммәтле эшләр башкарылу турында мәгълүматлар китеп тору очраклары ешайган, ә чынлыкта исә алар күпкә арзанрак булган. Стоматология клиникаларының берсе пациентларга өстәмә кабул ителүләр язып барган. Ә Әлмәт шәһәр балалар хастаханәсендә медицина страховкасына кертелгән процедураларның түләүле хезмәт күрсәтү очраклары ачыкланган.

ЯЛГАН АРХИВАРИУС

Казанда яшәүче берәү, утырган урыннан кузгалмыйча гына, керемле эш башлап җибәрергә булган. ТР Дәүләт архивының электрон версиясенә җиңел керү мөмкинлегеннән файдаланып, ул андагы документларны сата башлаган. Законсыз эшчәнлек алып барылуы ачыклангач, архив җитәкчелеге хәтта сайтны берничә көнгә ябып торган. Әмма ялган архивариус 125 мең сумны шудыртырга өлгергән.

УҢАЙСЫЗ ТӨРМӘ

Чаллыда бер бәндә вакытлыча тоту изоляторларындагы пычраклык, уңайсыз эскәмияләр, кыска караватлар һәм тиешле шартларга җавап бирми торган бәдрәфләргә судка зарланган. Шулай ук аңа бәдрәфнең җиһазлануы – вентиляция, иминлек каешлары булмавы һәм башка җитешсезлекләр ошамаган. Рухи һәм тән газаплары өчен "утыручы" 2,72 миллион сум таләп иткән. Шәһәр суды камерадагы бәдрәфнең кайбер шартларга туры килмәвен таныган һәм дәгъвачыга 10 мең сум компенсация билгеләгән. Үҗәт тоткын бу суммага риза булмаган һәм Татарстанның Югары судына мөрәҗәгать иткән. Ләкин Югары суд бәдрәфне физиологик ихтыяҗларны үтәү өчен яраклы дип тапкан һәм дәгъвачыны, гомумән, түләүдән мәхрүм иткән.



ГАЯТЬ ЗУР ПЛАННАР

Хөкүмәт юл кагыйдәләрен бозучылар өчен штрафлар җыюның планын арттырырга булды. Ел саен казна зуррак сумма белән тулыландырылырга тиеш булачак: 2024 елда – 52,8 миллиард, 2025 елда – 58,4, 2026 елда – миллиард сум. Мондый "планлаштыру" нәтиҗәсендә иминлек турында сүз бармый, әлбәттә – кагыйдә бозулар никадәр күбрәк булса, бюджетка шулкадәр күбрәк штраф керәчәк. Шуңа күрә безгә юлларда камералар, төрле "тозаклар" һәм беркетмәләрнең саны артуны көтәсе кала. Машина йөртүчеләр болай итеп акча суыртуга каршы чыга: "Халыкны талап күпме баерга мөмкин?!" Ә икенче яктан, бу уяулыгыңны көчәйтү һәм кесәңә керергә теләүчеләрне тыярга этәргеч булып тора.

ТИМЕР ЛОГИКА

Тәртипле машина йөртүчеләргә карата кызыксындыру чаралары кулланмаска булдылар. Ел буена бер тапкыр да кагыйдә бозмаганнарга транспорт салымының 50 процентын гына түләтү турындагы закон проекты үтмәде. Хакимият үзенчә хәл итте: салым хезмәте алдында барысы да тигез булырга тиеш – тәртипле йөртүчеләр дә, кагыйдә бозучылар да! Ә беренчеләре болай да яхшырак хәлдә – штраф түләмиләр, димәк, акчалары янга кала. Тимер логика – башка берни дә әйтеп булмый!


СТАТИСТИКА БАРЫСЫН ДА БЕЛӘ!

Бу елның тугыз ае эчендә иң күп юл-транспорт вакыйгалары Мәскәүдә (8,4%), Краснодар краенда (6,9%) һәм Мәскәү өлкәсендә (6,1%) теркәлгән. Алардан соң исемлек буенча Новосибирск, Ростов, Чиләбе өлкәләре, Башкортстан һәм Приморье крае бара. Татарстан бу "кара" исемлеккә эләкмәгән. Иң тәртипле юл хәрәкәтендә катнашучылар Свердловск, Омск һәм Волгоград өлкәләрендә яши. Шуны да әйтергә кирәк: Россиядә яшәүчеләрнең 95 проценты идеаль йөртүчеләр булуына ышана, ә 12 проценты үзләрен шундый дип саный.

БОЛАЙ ДА ҖИТӘРЛЕК

Балалы гаиләләргә ана капиталын автомобиль сатып алуга тотуны рөхсәт итү турында сөйләшүләр беренче ел гына бармый. Бу тәкъдимне хуплаучылар да, кабул итмәүчеләр дә җитәрлек. Соңгылар санына күп балалы һәм инвалид балалары булган гаиләләргә ана капиталын Россия автомобиле алу өчен тоту турындагы закон проектын кире каккан Министрлар Кабинеты да керде. Анда күп балалы гаиләләрнең Россиянең төрле өлкәләрендә болай да транспорт белән бәйле льготалары җитәрлек, дип санныйлар икән. Мәсәлән, аларга шәһәр транспортында бушлай йөрү рөхсәт ителә. Өстәвенә, алар фикеренчә, бу мөмкинлектән мошенникларның файдалануы мөмкин ала, имеш.

Валентин ДРУЖИНИН



Игорь КИЙКО



Ринат МИРЗАЯНОВ





ӘЙТЕГЕЗ, КЕМ ХАКЛЫ?

Хәмид ВӘЛИДИ

Беркөн мине карчык тәнкыйтьләде,
Сакалымны шактый агартты.
Бастырды да утлы табасына,
Коңгырт күзләренә каратты.
– Мин тормышта юлдаш булдым сиңа,
Кояш белән Ай күк яшәргә.
Янында мин була торып, ни дип,
Күз саласың һаман яшьләргә?
Үз хәлеңне күптән белер вакыт,
Әтәч сыман шашып сикермә.
Болай булсаң, күп сорамам мин дә
Егетләргә керфек сирпергә.
Ояла бел бераз оныклардан,
Янында мин барын онытсаң.
Үрнәк булыр идек без аларга,
Тузган оябызны ныгытсаң.
Эшне әнә кәстрүлдән башла,
Тоткасы юк, төбе тишелгән.
Сөяк-аркаң дуга була язган,
Кендек җебең тузып чишелгән.
Базар чоры хәзер, тотармын да,
– Нәсел әтәче! – дип, сатармын.
Утыз өч ел бергә гомер сөрдек,
Шәп беләсең мишәр-марҗасын.
Тәнкыйтьләде беркөн карчык мине,
Судан алып, утта көйдерде.
Үзенеке итте тәки җанкай,
Көйдерүе белән сөйдерде.
Киләчәктә бер хәл кылмый булмас,
Яңартырга кирәк никахны.
Күпме күтәрсәң дә хак сүз җиңел,
Күтәрүе авыр нахакны.
...Яшьләрне мин кызыгудан түгел,
Аңлап булмасмы? – дип, күзәтәм.
– Татар кызы, милләттәшем! – диеп,
Бәхет юрыйм һәм дә үз итәм.
Әйтегезче, дуслар, кем хаклы?!

МАКСАТ

Максат куйдым.
Зур һәм бик кыюны,
Һәм матурны – менә, карагыз;
Кояшсыз киң дөнья булмаган күк,
Яши алмый кеше максатсыз!

Олуг планнарым билгесен мин
Бизәкләп һәм сырлап эшләдем;
Ныклык өчен биек постаментын
Затлы гранит белән тышладым.

Ошбу максат минем тормышымны
Киләчәгем белән бәйләде.
Мәңге торыр хәзер зур юлымда
Минем көчле рухым һәйкәле!

Ринат АБЗАЛОВ





ПОЛИЦИЯДӘ ҖИТМӘҮЧЕЛЕК

Эчке эшләр министрлыгында 100 мең хезмәткәр җитми. Бер ай эчендә 5 мең полиция хезмәткәре эштән киткән. Бу хәл критик сызыкка барып җиткән – җинаятьчелекнең артуына китерергә дә мөмкин. Кадрлар агылуның төп сәбәбе – хезмәт хакы дәрәҗәсенең җитәрлек булмавы, зур эш йөге һәм чиксез бюрократия. 2024 ел бюджетында полиция хезмәткәрләренең хезмәт хакын планлаштырылган индексацияләү каралмаган.

ОЧРАШУ

Кайбер полиция хезмәткәрләре дәүләттән шәфкать көтә, икенчеләре үзләре акча эшли. Санкт-Петербургта Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре кызларны алдау схемасын уйлап тапканнар. Социаль челтәрләрдә хатын-кызлар белән чибәр егетләр танышып, интим танышудан соң егет караватт янындагы тумбочкада акча калдыра. Аннан гаҗәпләнгән корбан бүлмәсендә полицейский пәйда була һәм кыздан «Фахишәлек» статьясы буенча аны җәлеп ителмәс өчен 50 мең сум таләп итеlә. «Хокук саклау органнары хезмәткәрләренә» каршы җинаять эше кузгатылган, чибәр егетләр беркайда да китмәү турындагы язуга кул куйган.

ИШЕК ТОЗАГЫ

Мәскәүнең гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан коткаручылар командасы ишек бикләнеп калган чакыруга барганнар. Эшне тәмамлагач, хезмәткәрләр йозакларның дөрес эшләгәнен тикшерергә булганнар. Ишек тагын ябылып калган, ләкин бу юлы хокук саклау органнары хезмәткәрләре белән бергә. Кораллар тышта калган сәбәпле, бикне кабат җиңел булмаган. Фатирда бикләнеп калган коткаручылар хезмәттәшләрен чакырырга мәҗбүр булганнар. Ярдәмгә килгән икенче бригада аларны коткарган.

ЯЛКАУЛЫК


Черногориядә ялкаулык чемпионаты тәмамланган. Конкурста 21 уенчы катнашкан. Аларның төп бурычы – ял итү, йоклау, уку һәм ашау. 8 сәгать эчендә бер тапкыр гына торырга рөхсәт булган – бәдрәфкә барыр өчен. Җиңүче – 50 көн эшсез яткан кыз. Аның приз акчасы – 1000 евро.

АККА КАРА БЕЛӘН

Валентин ДУБИНИН



Виктор ФЁДОРОВ



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Йөреп калыйм...

Өлкән яшьтәге күршем бар. Кайчан карама, шифаханә юлында ул.

– Сәлам, Мәдинә апа! Кая ашыгасың иртә таңнан? – дип сорадым бервакыт.

– Табибка язылган идем, шунда барам.

– Нәрсә, авырыйсыңмы әллә?

– Юк ла. Болай, тикшеренергә генә.

Икенче юлы тагын каядыр ашыга бу.

– Диспансеризация үтеп йөрим. Сөйләшеп торырга вакытым юк.

Берничә көннән.

– Ничек, үтеп булдымы диспансеризацияне? – дим.

– Үттем, – ди. – Тик менә бик ышанып бетмим мин аларның язганнарына. Түләүлегә барып тагын тикшеренмәкче булам.

Менә бит тиктормас кеше: бушлай дәвалаучыларга да ышанып бетми, түләүлеләргә дә. Инде үзе дә буталып беткәндер.

– Мәдинә апа, ник шулай еш йөрисең син шифаханәләргә? Үзең берни дә авыртмый дисең бит.

– Әй, яшь чакта вакыт булмады йөрергә. Хәзер йөреп калыйм, дим. Көндезге стационарга да язылмакчы булам. Артык булмас.

Шулай итеп көн дә юлда, көн дә табибларда ул. Бер көн дә өйдә утырмый.

Табиблар да, күрәсең, моңардан арыганнардыр.


– Менә бит, хирургка кергән идем, аяк боттан авырта, нишлим икән, – диебрәк зарлана башлады күршем. – "Апа, өстәл почмагына ышкы авырткан ул җиреңне, булыша дип әйтәләр", – диде хирург. Андый дәвалау буламыни? Массаж кирәк миңа, ә ул бирми. Өстәл почмагына ышкылып дәваланган кешене күргәнем юк иде әле минем.

– Мәдинә апа, ә син чынлап та шулай итеп кара, бәлки, ярдәме булыр.

– Әй күрше, мин бит әле 75 яшемә җитмәгән. Шуңа күрә йөреп калыйм дим табибларга. 75 тән соң көндезге стационарлар да, хастаханәләр дә алмыйлар икән өлкән кешеләрне дип ишеттем. Шуңа тикшеренеп калыйм. Картлыкны сәламәт килеш каршыларга кирәк.



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Дамир МОРТАЗИН

Талаучы һәм сатучы

Ябылыр алдыннан ашамлык кибетенә бер кеше килеп керде. Битенә маска кигән. Уң кулында пистолетка охшаган нәрсәдер, сулында – спорт сумкасы. Өстәл каршысына басты да:

– Кулларыгызны күтәрегез! – дип кычкырып җибәрде.

Урта яшьләрдәге сатучы ханым, иренеп кенә, аны тыңлап кулын күтәрде.

– Акчаларыңны бир!

– Ничек бирим ди, минем куллар күтәрелгән бит?

– Шаярмыйча гына! Төшер дә акчаларыңны ал! Юкса үзең беләсең нәрсә булачагын... – дип, катырак кычкырды талаучы, пистолетын төбәп.

– Тапкансың нәрсә белән куркытырга! – диде сатучы. – Миңа барыбер. Мин – ятим, ирем ташлады, сөяркәм юк, балаларым да... Берьялгызым дөньяда...

Касса тартмасын чыгарып, ул талаучы алдына бигуди будыргычы белән бәйләнгән акча ташлады.

– Монда йөзлекләр белән өч мең сум... Тагын вак акча бар...

– Бик тә аз җыйгансың көне буена сатып... – дип, башын селкеде талаучы.

– Нишлим соң? – диде җавабында ханым. – Начар көн – халык хәзер акчасыз... Ә хуҗам акыра-бакыра: сата белмисең, ди. Куып чыгарам дип куркыта... Бәлки чәйләтә алырсың?

– Ә нәрсәгә миңа чәй? – дип гаҗәпләнде талаучы.

– Ничек инде? Кайда барсаң да, чәй бәһале... Миңа гына ул барыбер, ә сиңа иректә әле әйбәт.

– Нәрсәсе? – дип пистолетын төзәп торудан туктады талаучы. – Мин дә ялгыз. Хатын ташлады: булдыксыз белән яшисем килми ди...

– Шуннан? – дигән сүзен әйтеп куйды кызгангандай аны сатучы.

– Менә исбатлыйсым килде аңа минем нәрсәгәдер яраганымны...

– Димәк, сез дә беләсез ялгызлыкның нәрсә икәнен?

– Әйе... – талаучының тавышы калтыранып чыкты, ул пистолетын биле артына тыгып куйды.

– Борчылмагыз, сезнең әле тормышыгызны яңадан башларга мөмкинчелегегез бар...

– Ләкин ничек?

– Ялгызлыкның нәрсә икәнен белүче хатын-кызны очрату кирәк, сезне аңлаучыны...

– Сезнең кебекнеме?

– Шундыйракны дип әйтимме...

– Ә сез...


Талаучы нәрсәдер сорамакчы иде, өлгермәде. “Идәнгә!” дигән тавыш яңгырады, һәм ул камуфляжлы каты куллы кешеләр чолганышына эләкте.

Әйе, сатучы талаучыны сөйләштереп торган арада, сиздермичә генә хәвеф хәбәре бирә торган кнопкага басарга өлгергән иде.

Валентин ДУБИНИН




Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО



Николай **ВОРОНЦОВ**



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ...

Әгәр синең буш вакытың барлыкка килгән икән, димәк нәрсәнедер эшләргә оныткансың.

Кайчагында ялган да дөрес булырга лаек.

Чын күңелеңнән тәүбә итәр өчен, җаның-тәнең белән гөнаһ кылырга кирәк.


Акчаның исе юк, бигрәк тә ул булмаганда.

Безнең вакытта бөтен билгеле нәрсә сергә әйләнә.

Цивилизация артыннан куам, дип, кыргыйга әверелүең мөмкин.

Яшь барган саен, йөрәк серләре йөрәк авыруларына әйләнә.

Александр **ШУЛЬПИНОВ**





Илдар ӘХМӘДИЕВ, 2003 ел.



Виталий ФЕОКТИСТОВ, 1997 ел.

Илдус ДИНДАРОВ

ИХТЫЯРСЫЗДАН ГАРМУНЧЫ

– Мин бит, малай, ни чарадан бичара гына гармунга ябыштым,"колагыннан" тартып уйнарга өйрәндем, – дип сөйли авылның иң оста гармунчысы саналган Мидхәт абзый. – Ышанмыйсызмыни? Соң, үзегез дә беләсез, безнең нәсел-ыруда аны тотып та караган кеше юк. Ә минем белән болай булды... Яшь чакта нифте эшендә буялып йөрдем бит мин... Яхшы бригадка эләктем. Ай буена ялан кырда. Ашау-эчү бергә, табындагы уртак дигәндәй. Эчем-төчем чутыннан, ул "шайтан суын" вагонда ни-ни. Ну, вахтаны тапшырып, кайтырга чыккач, тугарылабыз инде!

Авыл читендә бораулаган вакыт. Кайтышлый, аракы эзләп, иске алачык кәмәшедәй кибеткә килсәк, сатучы хатын "юк", дип, башын гына чайкый. "Сухой закун", теге дә бу. Үгетли, ялына торгач, бер "ярты"ны чыгарды тагын. Дүрт-биш борынга нәрсә инде ул?! Нагрузкага ияртеп, тагын бер литрны өстәде. Нагрузкасы да нинди әле – тальян гармун! Бәясе дә үзенең... Ат бәясе! Нишлисең, һичкем маташтыра белмәсә дә, сатып алмый хәлебез юк. Алдык, арабызда иң яше мин булганга, "Әнә Мидхәт өйрәнсен" – дип, миңа тоттырдылар. "Безнең эштә музыкасыз булмый ул. Алган малны әрәм итәргә ярыймы соң", диештеләр. "Кара аны, телевизордагы баянчыдан ким уйнарлык булмасын штубы. Таза өйрән!" – дип бармак янады таләпчән бригадирыбыз Галим абый. Шулай итеп, көчләп диярлек гармунны тактылар да куйдылар муенга. Көй-фәлән чыгара алмаудан гарык булып, ачудан атып бәреп эшкә ябышсам, янә куып кертәләр. "Бар, өйрән, и вчу!" Көне-төне шуның белән чиләндем. Бию көйләре чыгарырлык булдым тәки. Аннан соң инде бүтәненә кул шомарды. Ну инде, аннары бригадым белән саубуллашырга туры килде, нефтьчеләр клубына баянчы итеп кодаладылар.

КЕМ ЙӨРИ АНДА?

Сугыштан соңгы авыр еллар. Авыл халкы ачлыктан киселгән чак. Аеруча бала-чага интегә. Бер көнне олы-кара уракка киткәч, алты яшьлек Хәйри күрше өйгә кергән дә, почмакта, кәсәгә салынган аертылган зәңгәрсу сөтне карт мәче белән беррәттән чупырдата башлаган. Түр сәкедә дөм сукыр Хуҗиәхмәт бабай утыра икән. "Кем йөри анда?" – дигән ул, ишек катында кыштырдаган тавышка башын борып. Карак малай да аптырап калмаган, картның ун яшьлек оныгына сылтап, "Кем булсын! Хәлим абый!" – дип, чатнатып җавап кайтарган да чыгып сызган.


СӘЛӘТ

– Мәҗлескә баргач, "Йөзек салыш" уенында утырган идем. Җәзасын үтәргә кирәк бит инде. Мин бии дә, җырлый да белмим, рөхсәт булса, ашап күрсәтер идем, дидем дә бер утыруда ике тутырган тавыкны, зур табак бәрәңгене бөкләп салдым. Артыннан бишме-алтымы шешә сыраның эшен китергәч, шуларны ике стакан аракы белән бастырып куйдым. Аннары тагын...


– Йә, йә, шуннан?

– Шуннан – шул, бүтән кунакка чакырмый башладылар. Сәләтемнән көнләшәләр...

Валентин ДУБИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Наркологта:
– Эчәсезме?
– Эчәм.
– Көн саенмы?
– Көн саен, баш күтәрми эчкән чаклар да булгалый.

• • •

– Хатыныңа кайчан чәчәкләр бүләк иттең? 8 Мартка гына, туган көненә генә түгел, ә болай гына?
– Әйе, бүләк итеп кара син аңа. Шундук шикләнүләре башлана, төпченергә керешә. Шунда барыбер нәрсә булса да таба бит.

• • •

Бер кешегә болай дип юраганнар: ул ниндидер бәхәс нәтиҗәсендә үләчәк икән. Шул вакыттан соң бу башкалар белән бик сак сөйләшә башлаган, ягымлы кыланган, гел аларга баш иеп, бил бөгеп кенә торган. Ләкин берзаман бик каты авырып киткән, һәм аның караваты янында табибларның консилиумы җыелган.

• • •

– Сез эшәке итеп сүгенәсезме?
– Сүгенү генә түгел, мин әле мактарга да яратам шулай итеп.

• • •

Банктан шалтыратып әйтәләр: минем счётта хәвефле активлык барлыкка килгән. Кем дә булса акча салды микән әллә?

• • •

Ипи – күп кулланыла торган ризык. Пешерүе бик гади: он, су, чүпрә, шикәр... Гәрчә он катнаштырмасаң, тагын да күбрәк кулланыла торган нәрсә килеп чыга...

• • •

– Бөтен гамәлне цифрлаштыру бик зур темплар белән бара: хәзер рәхәтләнеп җайлы гына Интернет аша дәвахәнә терапевтына язылырга мөмкин.
– Әйе, килгәч, сорарга онытмагыз: "Чиратта кем соңгы?" – дип.

• • •

Урманда ишәк белән жирафка каты шелтә белдерәләр, хәтта утырта да язалар. Ишәккә – кирелеге өчен, ә жирафка теләсә кая кысылып йөргәне өчен.

Ләкин урманда переворот ясала. Ишәк белән жирафка рәхмәт белдерәләр. Ишәккә – принципиальлеге өчен, жирафка еракта күрә белгәне өчен.



ЧАГЫШТЫРМАЛЫКТАГЫ СУ

Кадерле "Чаян"! Дөньяда барысы да чагыштырмача икәнлеге барыбызга да мәгълүм. Хәтта шундый теория дә бар. Без, Осиновода яшәүчеләр, бу турыда башкаларга караганда ныграк беләбез. Мөнә инде ничә еллар буе безнең бистәдәгеләр суүткәргеч торба аша килә торган судан башка яши. Хакимияттәгеләр моны торбаларның бөтенләй тузып беткәнлегенә сылтый. Яшәү өчен җай табу мөмкинлеген үзебезгә тапшырганнар. Еллар үтә торгач, һәр йорт су чыганагын үзенчә хәл итте – ул хуҗалары тарафыннан нык сакта тора. Инде бу турыда байтак даирәләргә хәбәрләр дә бирелде. Тамчы таш тишә ди, ниһаять, үткән ел су тоту урыны төзелде, яңа торбалар салынды, коеларга гидрантлар куелды. Югыйсә инде краннардан күптән көтелгән су агарга тиеш иде. Ләкин җәй буе кирәкле документлар җыеп тапшырылса да, "Водоканал"га мөрәҗәгать ителгәннән соң без рөхсәт ала алмадык – бюрократик чуалчыклар аркасында бу өмет киселгән, ягъни мәсәлән, предприятие балансына кучерелмәгәнлек беленде. Әлеге дә баягы чагыштырма теориясе буенча су барлыгы дөрес, ә чынлыкта ул юк – тамчысы да. Безгә һаман вәгъдә бирәләр, тиздән булыр, диләр. Кызганыч, "тиздән" дигән аңлатма – шундый ук чагыштырмача нәрсә.

Осиново бистәсе халкы

ЯШЕЛ ҮЗӘН р-ны


КҮНЕГЕЛГӘН ГАДӘТ БУЕНЧА

Хөрмәтле редакция! Бик озак еллар буе Рихард Зорге урамындагы 38 нче йортта яшәүчеләр ишегалдына керешле итеп юл салдыруга ирештеләр. Ләкин әлеге үтенечебез үтәлгәнче, һәр соравыбызга мондый канатлы фраза яңгырап торды: "Акча юк, әмма сез түзегез". Ахыргача түздек, һәм күптән түгел көтелгән өметләр акланды. Акча да табылган, инде яңа асфальт та җәелде. "Хәерчегә җил каршы" дигәндәй, бәхетсезлеккә, бер ай да үтмәде, яңартылган юл астындагы торба ватылды. Аны ничек кирәк ремонтлап куйдылар да, инде өстенә асфальтын әллә ни рәтләмичә генә сыладылар. Хәзер ул юл элеккегесенә караганда да әшәкерәк хәлгә килде. Инде без яңадан юлыбызны ремонтлы чактагы матур рәвешкә китерүне сорап, ялынырга мәҗбүр булдык. Күңелдәге тагын теге таныш фраза яңгырый башлады: "Түзегез" дигән. Хәзер бер генә нәрсә куандыра: кайда, ничек һәм ничә мәртәбә шикаять язарга кирәклеген беләбез.

Р. ЮТУСОВ

КАЗАН

Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



ИГЪТИБАР, КОНКУРС!

«Чаян» («Скорпион») журналы редакциясе соңгы вакытның актуаль вакыйгаларына: Украинадагы кризис һәм МХО, коллектив Көнбатыш белән каршы тору, Россиягә каршы санкцияләр, НАТОның агрессив политикасы, «бишенче колонна», куркынган «патриотлар» һ. б. темаларга багышланган сәяси карикатура конкурсы игълан итә. Барча патриотик карашлы һәм битараф булмаган авторларны катнашырга чакырабыз. Эшләрегезне 1 ноябрьдән 31 декабрьгә кадәр JPG форматында chayan@bk.ru электрон почтасына йә 420066, Казан шәһәре, п/о 66, а/я 48 адресы буенча «Конкурска» билгесе белән редакциягә җибәрә аласыз.

Җиңүчеләрне түбәндәге бүләкләр көтә:
1) беренче урын өчен 30 000 (утыз мең) сумлык бер премия,
2) икенче урын өчен 20 000 (егерме мең) сумлык ике премия,
3) өченче урын өчен 10 000 (ун мең) сумлык өч премия.

Конкурсның шартлары белән chayan-journal.ru сайтында танышырга мөмкин.



Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев Саратов өлкәсе, Кузнецк районы, Татар Кынадысы авылында крестьян гаиләсендә туа. Ул башта авылда, аннан соң Самарада укый. Шул чагында атаклы рус язучысы Александр Неверов җитәкчелек иткән әдәбият түгәрәгенә йөри, шигырьләр яза башлый. Аңа В. Маяковский поэзиясе зур тәэсир ясый, һәм ул футуризм белән мавыгып китә.

Егерменче еллар башында Казанга килә һәм Казан шәрык педагогика институтында укый. Шул ук вакытта үзенең берече шигырьләре белән матбугатка чыга. Соңрак, шигырь язу белән беррәттән, хикәяләр, драма әсәрләре һәм күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре яза.

Аның "Җавап" (1929), "Шатлык җыры" (1936) пьесаларында, поэма һәм җырларында яңа тормыш төзүче халыкның тормышы күрсәтелә. 1939 елда "Тапшырылмаган хатлар" исемле атаклы повесте дөнья күрә. Бу әсәр бик күп телләргә тәрҗемә ителә. Америкада, Европа илләрендә басылып чыга.

Г. Кутуй Бөек Ватан сугышына үзе теләп китә. Күп кенә бәрелешләрдә катнаша, фронт газетасында эшли. Күрсәткән батырлыклары өчен хөкүмәтнең орден һәм медальләре белән бүләкләнә.

Сугыш шартларында да ул актив иҗат эшчәнлеге алып бара. Патриотизм белән сугарылган күпсанлы шигырьләр, хикәяләр, очерклар яза. 1944 елда исә ул Казанга, иҗади ялга кайта һәм «Рөстәм маҗаралары» дигән маҗаралы-фантастик повестен иҗат итә.

Гадел Кутуй фашизмга каршы соңгы сугышлар вакытында Польшада госпитальдә вафат була.

ТУГАН ИЛ

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дәле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

ИРТӘНГЕ УЙЛАР

Алтын колач җәеп кояш калка,
Җылы нурлар җиргә тарала;
Кояш матурлыгын кочар булып
Мин тез чүгеп карыйм аңарга.

Окоп янындагы күл төбендә
Мин күрәмен нурлар уйнавын;
Нурда, саф һавада коенам мин,
Җиңел булсын диеп юлларым.

Мин исним дә сирень чәчәкләрен,
Дошман якка карыйм һәм көләм;
Шушы сирень чәчәгендә чөнки
Җиңү музыкасын ишетәм.

Автоматым кысып, горур атлап,
Ап-ак төнге юллар үтәм мин,
Чөнки һәрбер тыныч адымымда
Җиңү музыкасы ишетәм мин.

Юлларымда күрәм туп, танклар,
Һәм күрәм мин халык яуларын.
Бронзадай гаскәр сафларында
Мин ишетәм хаклык яңравын.

Хыял күзем белән илгә карыйм,
Карап туймыйм – рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә!

ОЗАТУ ҖЫРЫ

Сау бул, улым, чиккә оч син;
Бәхет яусын юлыңа.
Завод өчен тыныч бул син:
Анаң кала синең урыныңа.

Лачын коштай очып,
Дошманны ку иленә;
Яшен ташы булып оч син,
Оч син фашист өстенә!

Бомбаларың туры төшсен,
Бетсен этләр оясы;
Биегрәк күтәрелсен
Алсу ирек кояшы.

Сәлам хатың килгән саен
Бәйрәм күлмәк киярмен.
Минем улым батырларча
Бурычын үти, диярмен.

Мин көтәрмен кайтуыңны,
Сине каршы алырмын.
Син күрсәткән батырлыкны
Орденыңнан танырмын.

Сау бул, улым, чиккә оч син;
Бәхет яусын юлыңа.
Завод өчен тыныч бул син:
Анаң кала урыныңа.

БАТЫР КАБЕРЕНДӘ

Ялгыз кабер тора тау башында,
Яшь бер батыр анда күмелгән:
Таңда искән кыр җилләре аңа
Күп-күп итеп чәчәк китергән.

Баш очында аның шаулый нарат,
Ә наратта кошлар сайрыйлар.
Эссе көндә аны каплый болыт,
Ә суыкта – нурлар карыйлар.

Бер яшь батыр ята тау башында,
Дусты килгән аны күрергә.
Ул ант итә аның баш очында
Дошманнарга җәза бирергә.

– Мин ант итәм үбеп туфрагыңны,
Мин ант итәм синең кабреңдә,
Һич кызганмам явыз дошманнарны
Син яшәрсең минем хәтеремдә!

Алмаз ХӘМЗИН

Рәхәтләнеп көлерлек хәл...

Бар иде бит шундый чаклар... Бөтен шәһәр кешесенә якын-тирәләрдән бакча өчен җир өләшү. Баштарак кайбер оешмалар аны үзләренең эшчеләренә бушка, ягъни түләүсез-нисез дә тәкъдим итә иделәр. Соңрак бәя ачтылар, әллә ни үк кыйбат түгел бәягә сата башладылар. Инде алырга теләмәсәң дә, үгетләп, көчләп тагалар. Минем үземә, мәсәлән, ул җир кишәрлекләрен профком рәисе белән өләшеп йөрергә дә туры килде. Кайберәүләр бер өлеш түгел, өчәр-дүртәрне комсызланып алдылар. Ә мин, ә минем уемда да юк бу турыда уйлау. Кая анда алты сутый җир хуҗасы булу, әле яшәр өчен юньле урын да юнәтә алмадым, гаиләм бар – тулай торакта җан асрыйбыз. Ә монда җир алырга кушалар – нишлим мин аның белән? Аны бит карап торырга кирәк – эшкәртергә, утыртырга, барып йөрергә, нәрсәдер төзергә; ахыр чиктә – артык акчасы да булырга тиештер бит. Аларның миндә берсе дә юк һәм алда да күренми... Шулай, профком рәисе белән кем тели шуларга өләшеп бетердек без бу җирне. Булышуым өчен зур рәхмәт әйтте начальнигым. "Ярый әле алмадым", – дип, мин дә куанып куйдым.

Еллар үтте, фатирлы булдык. Халык әле һаман котырып җирләр ала. Инде Иделнең бу ягыннан җирләр бүленеп бетерелде. Казан халкы теге ягына чыкты. Миңа яңадан тәкъдим итәләр: "Ал, менә бик шәп җирдән! Милицияләр белән бергә – Идел кырые!"

Чыннан да, куанырлык тәкъдим бит. Җитмәсә, зур елга ярында ди – бик тә элитный урындыр... Милицияләр белән бергә тынычрак та булыр... Юкса жуликлар күп бит, бакча талап йөрүчеләр.

Биреләсе участокның дүрт почмагын билгеләп кую өчен, дүрт казык алып, мондый бәхеткә ирешкән кешеләр белән, УАЗ "Санитарка"га утырып, юлга чыктык.

Юлыбыз Югары Ослан күпере аша Идел аръягына чыгып, Мәскәүгә таба икән. Алдагы тормышыбызның ифрат та гүзәл булачагына хисләнеп, байтак юл үтелде. Инде Идел дә артта калды. Мин пошынып:

– Идел кырыенда дигәннәр иде бит бакчаларыбыз! – дип әйтеп куйдым, машина тәрәзәсеннән як-якка каранып барганда. – Инде Идел артта калды бит...

Шофёр:

– Әле ул тагын күренәчәк! – дип, күңелгә җылымса өстәде.

Әйе, чынлап та, шулай икән шул. Әнә бит, Идел уртасындагы утрауда Зөя шәһәрчегенең биналары.

Мин кабат шофёрга ым кактым:

– Казаннан монда хәтле ничә километр булды? – дим.

– Илле биш, – ди.

Уйга калдым.

– Әле тагын барасымы?

– Әйе, әллә ни күп түгел инде...

– Да-а-а! – дип куештылар салондагылар, эчләре пошып.

Машина кисәк Иделдән туксан градуска борылып, еракта, бик ерката ялгызы гына күренеп торган чиркәү гөмбәзенә таба, инде асфальттан чыгып тузан тузгытатузгыта кыр юлына чыкты. Дөңгер-дөңгер байтак баргач, ниһаять туктап калды. Тузан бөркүеннән бернәрсә күрми зарыккан күзләребезне уа-уа тау башына төштек. Еракта, бик еракка хәтле иңкүлек җәелгән, каяндыр чыгып, бормаборма агым ясап, ниндидер елга ага.

Инде бөтенләй аптырашта калган юлчы-бакчачыларыбыз сорамыйча гына, бармаклары белән ишарәләп, шул елгага төртеп күрсәтәләр. "Яһәмәсе, Идел кайда? Ә бу нинди елга?"

Шофёр абзыебыз, шул ук вакытта җир бирүче инструкторыбыз да икән, әйтеп аңлатуны кирәк тапты:

– Бу Зөя елгасы!

Әйе, матурын матур икән дә бит табигате, әмма алтмыш километр юл йөреп, мондагы таш чыгара торган җиргә килеп, җәннәттәй бакча үстерү, ай-һай, хыялга сыяр микән? Язмышыма буйсынып, алып килгән казыкларымны күрсәтелгән участогымның дүрт почмагына, таш аралап, көчкә кагып куйдым да, инде монда хәтле килеп, үз кишәрлекләрендәге ташларны Чыңгыз хан гаскәриләренең походлы юлларында өеп, курганнар ясаганнарын уйлап утырдым. Башкалар да шулай тыныч кына иттеләр дә, көн кичкә авышкач, кире кайтыр юлга чыктык. Иделне кабат кайтыр юлда күрү күңелебезгә шатлык өстәмәде. Ул үзе дә моңсу гына ага иде.

Шул бер барып кайтудан соң ул якларга юлым төшмәде, гәрчә шул ямьлелеккә шактый гына акча түләнелсә дә. Шулай да милицияләр җаен тапканнардыр әле?.. Бездән хәер булыр...

Бу очрактан игътибарга лаек бер кызыкны да өстәп куйыйм әле. Күп еллар үтеп, инде әлеге вакыйга онытылып беткәч, күренекле язучыбыз Марсель Галиев кисәк миннән:

– Синең бакчаң кайда әле? – дип сорады.

Мин:

– Иделнең теге ягында! – дим.

– Анда гел байлар гына түгелме соң? – ди ул шаккатып.

– Соң, без бит инде ул! – дим җавабымда.

Рәхәтләнеп көлде инде...



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1936) ноябрь 2023

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш рәссам: А. АЛЁШИН

Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА

Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ

Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН

Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА

Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА

Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, РФ, РТ, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды. 420066 РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.

Чыгу көне: 01.11.2023 ел.

Тираж – 2605 Заказ С-2961

Редакциянең адресы: 420066, РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+




ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Валентин ДУБИНИН



